**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге башлыгы**

**КАРАР**

**14 ноябрь, 2022 ел.** **№ 4**

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 ел, 28 июль, 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Шәрбән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 ел, 25 ноябрь, 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Аксубай районы Шәрбән авылы Лермонтов урамы, 6 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлегенең Шәрбән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2022 елның 25 ноябрь 14.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Аксубай районы Шәрбән авылы, Лермонтов урамы, 6 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлегенең Шәрбән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлегендә яшәүчеләрнең исемлеген 2 өлешкә бүләргә:

1) Вахитов урамы, Елга урамы, Лермонтов урамы, Крылов урамы, Яшел урамы, Октябрь урамы, Совет урамы, М.Җәлил урамы, Газ урамы

2) Беренче май урамы, Кыр урамы,Пролетар урамы, Тукай урамы, Пушкин урамы, Үзәк урамы

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, беренче төркем

инвалидлардан, мобилизацияләнгән гранданнардан һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 1000 сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертү һәм алдагы эшләрне башкару буенча әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1. **Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына һәм җирлек торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге:**

*- Шәрбән авылы урамнарында вак таш түшәлгән юллар төзү (вак таш сатып алу, торбалар алу, грунт күтәрү, вак таш сибү, ташу, җәю, вак таш тигезләү, килешү буенча эш өчен түләү).*

*- Шәрбән авылы урамнарын агымдагы ремонтлау (вак таш сатып алу, вак таш салу, килешү буенча эш өчен түләү,)*

**2. Территорияләрне төзекләндерү:**

*- трактор өчен асылмалы җиһазлар алу;*

**3. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә, җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**

*- суэтем башнясы территориясен киртәләү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) Шәрбән авылы;*

*- Шәрбән авылының су башнясын буяу (материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү) ;*

*- Шәрбән авылының сууткәргечен ремонтлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)*

“ӘЙЕ” “ЮК”.

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда белдерү такталары һәм стендларда урнаштыру юлы белән, шулай ук Аксубай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә

Аксубай муниципаль районы
Шәрбән авыл
җирлеге башлыгы Д.Ә.Шәрифуллин